| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МӘРЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.06.2023 г.Лениногорск № 60

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2016 елның 29 июлендәге 101 номерлы карары белән расланган, муниципаль заказга кертелмәгән, Лениногорск шәһәре һәм Лениногорск районы маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 29 маендагы 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2016 елның 29 июлендәге 101 номерлы карары белән расланган, муниципаль заказга кертелмәгән, Лениногорск шәһәре һәм Лениногорск районы маршруты буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8.16 пунктның 3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) юридик зат, шәхси эшмәкәр яки гади ширкәт килешүендә катнашучылар тарафыннан тәкъдим ителгән һәр класстагы транспорт чараларының ташу сыйфатына йогынты ясый торган характеристикалы өлешләре тиешле класстагы транспорт чараларының максималь санының процентларында;»;

4.1 пунктның 1 пунктчасында «пассажирлар» сүзеннән соң «һәм автобуслары булган башка затлар» сүзләре белән тулыландырырга;

4.1 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Россия Федерациясе салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пеняләр, штрафлар, процентлар буенча конкурста катнашучының ачык конкурста катнашуга гариза бирү датасына үтәлмәгән бурычы булмау;».

2.Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Р. Г. Хөсәенов

Галимова Л.М.
5-44-72